**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 28 июлендәге 2689 номерлы карары**

**Ел саен үткәрелә торган «Мин күкне сайлыйм»**
**авиация бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру чорында**
**Казан шәһәренең автомобиль юллары буена**
**транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында**

Ел саен үткәрелә торган «Мин күкне сайлыйм» авиация бәйрәмен уздыру көнендә иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк яки муниципальара, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү яисә вакытлыча туктату тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

**1. Карар бирәм:**

1.1. әлеге карарның кушымтасы нигезендә автомобиль юллары буенча, «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан билгеләнгән форма буенча махсус рөхсәтнамә белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, 2026 елның 1 августында 10.00 сәгатьтән 22.00 сәгатькә кадәр транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. Сибгат Хәким урамы буенча ике якка, Декабристлар урамы киселешеннән алып Әпсәләмов урамы киселешенә кадәрге участокта;

1.1.2. Бондаренко урамы буенча ике якка, Сибгат Хәким урамындагы 3 номерлы торак йорттан алып Сибгат Хәким урамына тоташкан участокта;

1.2. «Казан» гаилә үзәгенең күзәтү мәйданчыгына керү мөмкинлеген чикләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясенең кушымтада бирелә торган схемасы нигезендә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында юл билгеләрен урнаштыруда һәм аларны каплауда ярдәм күрсәтергә;

1.3.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми

порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарда күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эш оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе (Р.Х.Шәмсетдинов) белән берлектә юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары дислокациясенең кушымтада бирелә торган схемасы нигезендә хәрәкәтне вакытлыча чикләү чорында таранга каршы техника куюда ярдәм күрсәтергә;

1.5. «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.Ф.Латыйпова) әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән рөхсәтнамә үрнәкләрен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе бүлегенә тапшырырга;

1.6. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөклим.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 июлендәге
2689 номерлы карарына
кушымта

**Юл хәрәкәтен оештыруның**

**техник чаралары дислокациясе схемасы**

